УДК 930.253
EDN TWWPKP
DOI 10.24412/2073-7475-2026-4-105-113

Гази Кашшаф фондында Муса Җәлилгә бәйле материаллар (М. Җәлилнең тууына 120 ел тулу уңаеннан)

Л. Ш. Галиева,

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе

Materials on the life and work of Musa Jalil in the Gazi Kashshaf archival collection (on the occasion of the 120th anniversary of his birth)

L. Sh. Galiyeva,

Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan, the Republic of Tatarstan, Russian Federation

Аннотация

Статья представляет собой краткий обзор материалов из фонда татарского литературного критика, литературоведа и писателя Гази Кашшафа (Миргази Султанович Кашшафутдинов, 1907-1975), содержащих сведения о жизни и творчестве татарского поэта, Героя Советского Союза Мусы Джалиля (1906-1944). Данный фонд был сформирован в Центре письменного наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан на основе материалов, переданных супругой критика. В первой описи фонда материалы о поэте объединены в раздел «Работы о М. Джалиле», который состоит из нескольких подразделов: работы Г. Кашшафа о М. Джалиле и джалилевцах (1941-1975 гг.); произведения, письма, статьи, сметы, фотографии и другие документы М. Джалиля (1922-1942 гг.); материалы других авторов о М. Джалиле и джалилевцах (1934-1975 гг.). Несмотря на то что многие материалы о М. Джалиле были опубликованы литературным критиком, в архиве хранятся фотографии, отдельные статьи, газетные вырезки, заметки, воспоминания и другие записи как Г. Кашшафа, так и иных лиц. Эти документы позволяют дополнить картину жизни и творчества татарского поэта, открывают новые горизонты для исследователей подвига и творческого наследия М. Джалиля, а также его соратников. Материалы содержатся не только в разделе о М. Джалиле, но и в других описях литературоведа, что свидетельствует о необходимости более тщательного изучения архива в целом. Исследование архивного фонда раскрывает подробности творческой лаборатории литературного критика и близкого друга поэта.

Abstract

The article is a brief overview of the materials from the collection of the Tatar critic of the Soviet period Gazi Kashshaf (Mirgazi Sultanovich Kashshafutdinov, 1907-1975), which contain information about the life and

work of the Tatar poet and Hero of the Soviet Union Musa Jalil (1906-1944). This collection was formed in the Written Heritage Center of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan based on the materials donated by the critic's wife. In the first inventory of the collection, the materials about the poet are combined into the section "Works about M. Jalil", which consists of several subsections: works by G. Kashshaf about M. Jalil and his associates (1941-1975); works, letters, articles, notes, photographs and other documents of M. Jalil (1922-1942); materials of others about M. Jalil and his associates (1934-1975). Despite the fact that many materials about M. Jalil were published by the literary critic, the archive contains photographs, individual articles, newspaper clippings, notes, memoirs and other records of both G. Kashshaf and other persons, which allows researchers to complete the picture of the life and work of the Tatar poet and opens new horizons for studying the heroism and creative legacy of M. Jalil. The materials are contained not only in the section about M. Jalil, but also in other inventories of the literary scholar, which indicates the need for a more thorough study of the archive as a whole. The study of the archival fund reveals details of the creative laboratory of the literary critic and close friend of the poet.

Ключевые слова
Архивный фонд, Гази Кашшаф, Муса Джалиль, татарская литература, фотография, переписка, письма, воспоминания.

Keywords
Archival fund, Gazi Kashshaf, Musa Jalil, Tatar literature, photo, correspondence, letters, memories.

Рәхмәт сүзе
Мәкалә «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.

Acknowledgements
The article was prepared within the framework of the state program "Preservation, Study and Development of State Languages of the Republic of Tatarstan and Other Languages of the Republic of Tatarstan", with the financial support of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan.

2026 елда каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулды. Бүгенге көндә аның тормыш юлын һәм иҗатын яктыртып язылган хезмәтләр шактый санда булса да (бу фактны шагыйрьнең юбилее уңаеннан Р. Ф. Исламов тарафыннан чыгарылган биобиблиографик күрсәткеч тә раслый[1]), М. Җәлилне шагыйрь, тәнкыйтьче, журналист буларак өйрәнү эше дәвам итә. Әлеге юлда төп таяныч – шагыйрьнең язма мирасы һәм аңа бәйле тупланган төрле материаллар. Шуларның бер өлеше Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә (Мирасханә) тупланган М. Җәлил фондында саклана[2]. Фондның тасвирламасы, Г. М. Дәүләтшин һәм Ә. М. Сабирова тарафыннан төзелеп, 2005 елда киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгән иде[3]. Моннан тыш герой-шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын яктырткан кулъязмалар, документлар шул ук үзәкнең Гази Кашшаф фондында да саклана[4]. Мәкалә кысаларында нәкъ менә шул фондта саклана торган материалларга кыскача күзәтү ясала.

Татар совет әдәбиятының танылган тәнкыйтьчесе, әдәбият галиме, журналист Гази Кашшаф (Миргази Солтан улы Кашшафетдинов, 1907-1975) – М. Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнү фәненә нигез салучыларның берсе булып тора. Ул 1907 елның 15 апрелендә Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы Туймазы районы) Яңа Арсланбәк авылында дөньяга килә. 1924-1928 елларда Казанда Көнчыгыш педагогия институтында укый һәм 1975 елга кадәр татар совет әдәбияты мәйданында кайный: Татарстан дәүләт китап нәшриятында әдәби консультант, редактор булып хезмәт итә, дистә елга якын «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакторы вазифасын башкара, Бөек Ватан сугышы чорында Язучылар оешмасында референт-консультант, СССР Фәннәр академиясеның Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән лаборант булып эшли, сугыштан соңгы елларда Казан дәүләт университетында укыта, филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә ия була.



Г. Кашшаф. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 100 ф., 2 тасв., 10 сакл. бер.

G. Kashshaf. Written Heritage Center; Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, fond 100, series 2, file 10.

М. Җәлил һәм Г. Кашшафның танышу вакыты 1920нче елларның икенче яртысына туры килә дип фаразларга мөмкин. Язучы һәм тәрҗемәче Мәхмүд Максуд М. Җәлилнең «Иптәшкә» китабына бәйле түбәндәгеләрне яза: «“Иптәшкәнең” зур тарихи әһәмияте бар. Китапның титул битендә “Иптәшкә” исеме астында җәя эчендә “Теләктәшкә” дип өстәлгән. Менә хәзер минем кулымда шул китапның Муса үзе Гази Кашшафка бүләк итеп биргән экземпляры. Титул битендә, сул кырыйда, Муса үзенең аермачык укыла торган вак хәрефләре белән (гарәп алфавитында) түбәндәгеләрне язган: “Кәшшәфи дус! Синең йөзеңдә революция юлындагы чын иптәшем-теләктәшемне күрдем. Йөрәктән ачыклык – искренныйлык, простойлык, салкын канлылык, тирән уйлаучылык, керсез беркатлы дуслык – менә минемчә нинди сыйфатлар теләктәшләрне җәһәт якынайта һәм бергәләп һәр уйны ачык уртаклашырга, тәнкыйтьләшергә, тикшерергә, киңәшергә, төзәтешергә, булышырга нигез сала. Без дә шулай бергәләп үсик, бергәләп көрәшик. М. Җәлил, Мәскәү. 1929 – февраль 16”»[5]. Әлеге юллардан аңлашылганча, шагыйрь белән тәнкыйтьче арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнашкан була. Ф. Әгъзамов игътибарга лаек бер фактны искәртә:

«М. Җәлил Г. Кашшафка партиягә кергәндә рекомендация бирә, аның идеяләргә бирелгән, объектив, кыю, партиячел тотрыклы, җәмәгать эшләрендә актив булуын ассызыклый. Бу – М. Җәлил белән Г. Кашшафның дөньяга караш җәһәтеннән кардәшләр, рухи туганнар булуын раслый»[6]. Әлеге рекомендация Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә тупланган М. Җәлил фондында саклана[7]. 1940 елда язылган документта шагыйрь: «Иптәш Кашшафетдинов Миргазины (Гази Кашшафны) мин 1937 елдан (ә әдәбият буенча шактый элегрәк) беләм. Үзенең матбугаттагы әдәби чыгышлары белән иптәш Кашшаф миндә объектив, кыю һәм партияле-тотнаклы тәнкыйтьче һәм язучы тәэсире калдырды… Практик эш буенча мин иптәш Кашшафны соңгы 1939-[19]40 елларда аеруча яхшы беләм. Иптәш Г. Кашшаф актив җәмәгать эшчесе һәм гүзәл иптәш. Ул Татарстан Язучылар союзында зур җәмәгать эше алып бара һәм СССР Язучылар союзы идарәсенә даими, актив булыша. Иптәш Кашшаф яшь авторлар белән һәм иң яхшы китапларны матбугатка үткәрү буенча аеруча зур эш алып бара. Бу эштә ул үзен сизгер, кайгыртучан һәм объектив булышчы – барлык язучыларның дусты итеп таныты», – дип язып чыга[8].

М. Җәлил белән Г. Кашшаф арасындагы дуслыкның ныклыгы Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы елларда сынала. Шагыйрь фронттан Г. Кашшафка язган хатларын түбәндәгечә башлап җибәрә: «Кадерле дустым минем, Кашшаф!», «Кадерле Кашшаф дус!», «Кашшаф дус!». 1942 елның март аенда Малая Вишерадан язган хатында М. Җәлил әдәбиятчыга васыятен җиткерә: «Кадерлем минем, Кашшаф! Син минем иң якын һәм кайгыртучан җан дустым идең һәм шулай булып калдың. Минем шундый авыр көннәремдә син үзеңнең дусларча саф күңелдән язылган хатларың белән миңа ярдәм иттең, минем иҗатым, китабым һәм гаиләм турында кайгырттың. Мин чын күңелдән сиңа рәхмәт әйтәм. Ышанам, син хәзер дә мине онытмассың. Минем поэзиямне һәм минем гаиләмне җылы кайгыртучанлык белән чолгарсың. Әгәр мин һәлак була калсам, мин барлык иҗатымны тулысынча сиңа ышанып тапшырам. Васыятем шул: исән чакта язганнарымның барысы да тулысынча синең күзәтүгә бирелә, синең яклавыңа һәм кайгыртуыңа күчә. Мин шат, минем поэзиям ышанычлы кайгыртучан кулларга бирелә»[9]. Соңрак васыять рәсми хат буларак та килеп төшә.

Дустының васыятен үтәү юлында, 1942 елда Г. Кашшаф «Тупчы анты» исемле шигырьләр җыентыгын әзерли һәм бастырып чыгара. 1944 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Письмо из окопа» җыентыгы да турыдан-туры Г. Кашшаф тырышлыгы белән дөнья күрә. М. Җәлилнең фронттан хатлары килми башлагач та, Г. Кашшаф шагыйрь иҗатын пропагандалау эшеннән читләшми. 1947 елда басылып чыккан «Татар совет әдәбиятының 30 еллыгы» мәкаләсендә дә ул шагыйрь иҗатына туктала. Ә инде 1953 елда, шагыйрьнең исеме аклангач, М. Җәлилнең мирасын өйрәнүгә һәм пропагандалауга Г. Кашшаф саллы өлеш кертә. Шушы елдан башлап аның герой-шагыйрьне төрле яклап өйрәнүгә багышланган эшчәнлеге киң колач ала. Нәкъ менә шушы юнәлештә җыелган материаллар Г. Кашшафның Мирасханәгә тапшырылган фондында саклана. 1981 елда Г. Кашшафның архивын Мирасханәгә хатыны Асия ханым тапшыра. Материалларны 1999 елда Ә. М. Сабирова тасвирлап чыга. Әлеге архив фонды дүрт тасвирламадан тора һәм М. Җәлилгә бәйле материалларның күпчелеге

беренче тасвирламага, аның алтынчы бүлекчәсенә кертелгән. Ул «Муса Җәлил турындагы хезмәтләр» дип атала. Саклау берәмлекләренең гомуми саны 100дән артып китә. Г. Кашшаф архивында тупланган эшләрнең М. Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә багышланганнары вакыт ягыннан 1922-1975 елларны колачлый. Тасвирлаучы аларны берничә бүлеккә аерып чыгарган: Г. Кашшафның М. Җәлил һәм җәлилчеләр турындагы хезмәтләре (1941-1975); М. Җәлилнең әсәрләре, хатлары, мәкаләләре, фотосурәтләре һ. б. (1922-1942); М. Җәлил һәм җәлилчеләр турында башкалар тарафыннан язылган материаллар (1934-1975).

Фондның әлеге өлешендә, нигездә, тәнкыйтьченең төрле елларда М. Җәлил әсәрләрен, эшчәнлеген анализлап язган мәкаләләре, очерклары, шагыйрьнең томлыкларына язылган кереш сүзләре, искәрмәләре, аңлатмалары һәм башкалар тупланган. Аларның күпчелеге басылып чыккан. Шулар арасында Г. Кашшафның 1957 һәм 1961 елларда М. Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнеп язылган очеркларның караламалары, басмага әзерләнгән вариантлары да урын алган. Моннан тыш биредә шагыйрь турында газета һәм журналларда басылып чыккан язмалар, «Муса Джалиль» фильмына киносценарий вариантлары (татар һәм рус телләрендә), шагыйрь турында истәлекләр, хикәяләр дә тупланган. Язмалар арасында Г. Кашшаф тарафыннан рус телендә язылган «Муса Джалиль – журналист» мәкаләсе игътибарны җәлеп итә[10]. Тәнкыйтьченең басылып чыккан публикацияләре арасында мондый исем белән һәм шагыйрьнең журналист буларак эшчәнлеген аерым, шактый тулы яктырткан язмалар күренми, Г. Кашшаф очеркларында бу мәгълүматлар гомуми текст эченә кертелгән. Күп кенә истәлекләргә нигезләнеп иҗат ителгән мәкалә шагыйрьнең татар матбугаты үсешенә керткән өлешен күзәтергә мөмкинлек бирә. Билгеле булганча, М. Җәлилнең журналистлык эшчәнлеге киңрәк планда тарих фәннәре кандидаты, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Шәмси Хамматов хезмәтләрендә, мәкаләләрендә тикшерелә. Аның фикеренчә, «журналистлык эшчәнлеген М. Җәлил “Кызыл Татарстан” газетасы редакциясендә башлый»[11]. Г. Кашшаф исә әлеге юнәлештәге эшчәнлекнең башлангычы итеп төрле оешмаларда стена газеталары чыгаруын күрсәтеп уза[12]. Мәкаләдә шулай ук шагыйрьнең новаторлыгы да ассызыклана: М. Җәлил татар вакытлы матбугатында беренчеләрдән булып җыр текстларын ноталар белән бергә бастыра башлый[13].

Тәнкыйтьче М. Җәлилнең альбомын төзүдә катнаша, шуңа да Г. Кашшаф фондында шагыйрь, аның гаиләсе, туганнары, якыннан аралашкан кешеләрнең фотосурәтләре саклана. Шулар арасында, мәсәлән, М. Җәлил белән иңгә-иң көрәшкән Гайнан Кормаш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Ян Габдуллин, Андре Тиммерманс һәм башкаларның фотосурәтләре бар. Г. Кормашка бәйле фотолар аеруча кызыклы. Сугышның алгы сызыгында үзен батырларча тоткан көрәшче тыныч тормышта укытучы, артист буларак тарихка кереп кала. 1938-1939 уку елларында Актүбә тимерьюлчылар клубы каршында оештырылган татар драма түгәрәге М. Фәйзинең «Галиябану» әсәрен сәхнәләштерә. Спектакльдә Бәдри карт ролен Г. Кормаш башкара. Фондта көрәшченең аерым һәм шулай ук укытучылар арасында төшкән фотосурәтләре дә бар[14].

Тасвирламаның әлеге өлешендә М. Җәлилнең 1922-1942 еллар аралыгында язылган әсәрләре, мәкаләләре, үзе, туганнары, дуслары булган фотосурәтләр һәм башка материаллар да саклана. Мәсәлән, шулар арасында М. Җәлилнең



Актүбә тимерьюлчылар каршында оештырылган татар драма түгәрәге әгъзалары. Уртада Бәдри карт ролендә – Г. Кормаш. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 100 ф., 1 тасв., 260 сакл. бер.

Members of the Tatar drama club at the Aktobe Railway Club. Gainan Kurmash, in the center, as the old man Badri. Written Heritage Center, the Center of Written Heritage; Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, fond 100, series 1, file 260.

абыйсына бүләк иткән альбомы бар[15]. Бу альбом шагыйрьнең үзе ясаган рәсемнәре белән бизәлгән. Саклау берәмлекләренең бер өлешен шагыйрь тарафыннан язылган рецензияләр, театр постановкаларына карата бәяләмәләре, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен күтәреп чыккан мәкаләләре тәшкил итә. Алар рус һәм татар телләрендә язылган. Биредә шулай ук шагыйрьнең Г. Кашшафка һәм башка шәхесләргә язган хатлары урын алган. Шулар арасында М. Җәлилнең Волхов фронтыннан җибәрелгән соңгы хатлары да теркәлгән. «Отвага» газетасында басылып чыккан кайбер язмаларының күчерелмәләре да урын алган. Г. Кашшафны шагыйрьнең васыятен үтәүче, аның мирасын барлаучы буларак танып, композиторлар Ж. Фәйзи белән Л. Хәмиди дә М. Җәлилгә бәйле архив материалларын тәнкыйтьчегә тапшырган булалар. Фондта аларның күчерелмәләре саклана. Тасвирламага шулай ук М. Җәлил архивында сакланып калган журналлар да кертелгән («Кечкенә иптәшләр», «Октябрь», «Авыл яшьләре», «Азат хатын», «Белем», «Безнең юл» һ. б.).

Тасвирламага кертелгән материалларның бер өлешен Җәлил турында башка шәхесләр тарафыннан тапшырылган документлар, хатлар, төрле язмалар, истәлекләр тәшкил итә. Билгеле булганча, М. Җәлил турында сакланып калган истәлекләрне туплауны да Г. Кашшаф башлап җибәрә: «Муса турында истәлек кирәк! Шушы сүзләр белән мин кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем! Язучыларга, артистларга, композиторларга, белеш-танышларга, дусларга, көрәштәшләренә...



РЛКСМ комитетының Орск өязе бюросы. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 100 ф., 3 тасв., 236 сакл. бер.

Bureau of the Orsk Uyezd Committee of the RLKSM (Russian Leninist Young Communist League). Written Heritage Center, Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, fond 100, series 3, file 236.

Берсе дә тәкъдимемне кире какмады, бик яхшы эш, изге эш, диделәр, шундый истәлекләрнең киләчәк буыннар өчен аеруча кыйммәтле булачагын искә төшерделәр һәм... истәлекләр ява башларга тиеш иде, билгеле. Тик алай булмады...»[16]. Архивның әлеге өлешендә тупланган истәлекләрнең саны йөзгә якын. Әлбәттә, истәлекләр төрле характерда. Аларның бик аз өлеше генә бүген безгә таныш истәлекләр китабына кертелгән. Бу аңлашыла да, чөнки шагыйрьнең аралашу даирәсе шактый киң, ул төрле шәһәрләрдә яшәгән, төрле оешмаларда эшләгән. Заманында матбугат битләрендә Г. Кашшаф махсус рәвештә әлеге истәлекләрне соратып та язмалар урнаштырган була. Ул күпсанлы истәлекләр арасыннан нәкъ менә Җәлил шәхесен тулырак ачканнарын, аңа бәйле мөһим фактларны саклаганнарын укучыларга җиткерергә тырышкандыр. Истәлекләрнең күпчелеге әдәбиятчының очеркларына кертелгән. Шул ук вакытта, әлеге истәлекләр шагыйрьнең киңкырлы эшчәнлеген өйрәнү, аерым фактларны ачыклау юлында чыганак ролен дә үтәргә мөмкин.

Беренче тасвирламада М. Җәлилгә багышланган бүлекчәдән тыш, Г. Кашшаф фондының башка тасвирламаларында да шагыйрьгә бәйле мәгълүматларны туплап була. Мәсәлән, икенче тасвирламаның 58нче саклау берәмлегендә тәнкыйтьче герой-шагыйрьнең әсәрләрен басмага әзерләү вакытында килеп

чыккан кыенлыклар турында хәбәр иткән язмасы бар. М. Җәлилнең әсәрләрен бастыру мәсьәләсе өченче тасвирламаның 63нче саклау берәмлегендә дә күтәрелә. Редакцияләргә мөрәҗәгать итеп язылган хатларның берсендә Г. Кашшаф үзен «Мусаның тулы хокуклы духовный наследнигы», дип атый[17]. Өченче тасвирламаның 236нчы саклау берәмлеге булып Орск өязе РЛКСМ комитеты бюросының әгъзаларыннан торган фотоколлаж теркәлгән. Әлеге фотография шулай ук Оренбург дәүләт иҗтимагый-сәяси тарих архивында саклана[18]. М. Җәлилнең альбомнарына кертелмәгән әлеге фотоколлаж шагыйрьнең аралашу даирәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек тудыра, аерым шәхесләр турында хәбәр итә. Икенче тасвирламада теркәлгән почта материалларының (хатлар) зур өлеше тәнкыйтьченең М. Җәлилгә бәйле алып барылган язышуларыннан тора.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, хәзерге вакытта Г. Кашшаф фондында каһарман шагыйрьгә бәйле теркәлгән материаллар төрле характерда, төрле күләмдә, аларның сакланышы да төрле. Алар арасында М. Җәлилнең үз кулы белән язылган әсәрләр, мәкаләләр, хатлар һәм башкалар булган кебек, аерым шәхесләрнең шагыйрь белән бер очрашудан сакланып калган истәлекләре дә тупланган. Материалларның бер өлеше фәнни әйләнешкә кертелгән булса да, аерым фактлар, язмалар М. Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын тулырак күзалларга мөмкинлек тудыра, фәннең әлеге юнәлешен яңа мәгълүматлар белән баета, шуңа күрә аларны җентекләп өйрәнү сорала. Әлеге архив материаллары Г. Кашшафның иҗат лабораториясен өйрәнүгә дә чыганак булып тора.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. *Исламов Р. Ф.* Муса Җәлил: Биобиблиографик күрсәткеч. – Казан: ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2026. – 300 б.
2. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 10 ф.
3. *Давлетшин Г. М., Сабирова А. М.* Описание рукописей Мусы Джалиля: (Фонд поэта в ИЯЛИ). – Казань, 2005. – 356 с.
4. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 100 ф.
5. *Максуд М.* Сагынган минутларда (Муса Җәлил турында истәлекләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Б. 119.
6. *Әгъзамов Ф.* Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: сорок лет на Кремлевской: сборник / Сост. и ред. В. З. Гарифуллин, Д. В. Туманов. – Казань, 2002. – Б. 34.
7. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 10 ф., 3 тасв., 17 сакл. бер., 1 кгз.
8. Шунда ук.
9. *Җәлилов М. М.* Әсәрләр: 5 томда. 5 т.: Сәнгать турында мәкаләләр һәм хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – Б. 275.
10. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 100 ф., 1 тасв., 192 сакл. бер.
11. *Хамматов Ш.* Муса Җәлил – партия солдаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 10.
12. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 100 ф., 1 тасв., 192 сакл. бер., 2 кгз.
13. Шунда ук, 7 кгз.
14. Шунда ук, 260 сакл. бер.

15. Шунда ук, 200 сакл. бер.
16. *Кашшаф Г.* Муса турында истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 306.
17. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Ф. 100, 3 тасв., 63 сакл. бер., 2 кгз.
18. Оренбург дәүләт социаль-сәяси тарих архивы, 7931 ф., 1 тасв., 276 эш., 193 кгз.

Әдәбият исемлеге

Әгъзамов Ф. Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: сорок лет на Кремлевской: сборник / Сост. и ред. В. З. Гарифуллин, Д. В. Туманов. – Казань, 2002. – Б. 30-45.

Давлетшин Г. М., Сабирова А. М. Описание рукописей Мусы Джалиля: (Фонд поэта в ИЯЛИ). – Казань, 2005. – 356 с.

Исламов Р. Ф. Муса Җәлил: Биобиблиографик күрсәткеч. – Казан: ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2026. – 300 б.

References

Agzamov F. Galim. *Zhurnalist. Pedagog* [Scientist. Journalist. Teacher.]. IN: *Mezhdu proshlym i budushhim: sorok let na Kremlevskoj: sbornik. Sost. i red. V. Z. Garifullin, D. V. Tumanov* [Between the Past and the Future: Forty Years on Kremlevskaya: collection. Compiled and edited by V. Z. Garifullin, D. V. Tumanov]. Kazan, 2002, P. 30-45.

Davletshin G. M., Sabirova A. M. *Opisanie rukopisej Musy Dzhalilya: (Fond poeta v IYALI)* [Description of the manuscripts of Musa Jalil (Poet's Fund at the Institute of Languages, Literature and Art)]. Kazan, 2005, 356 p.

Islamov R. F. *Musa Djalil: Biobibliografik kyrsetkech* [Musa Jalil: Biographical Index]. Kazan: Institute of Tatar Eniclopedia and Regional Studies named after. M. Khasanova publ., 2026, 300 p.

Сведения об авторе

Галиева Ляйсан Шаукатовна, кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, e-mail: nisanbedri@mail.ru

About the author

Lyaysan Sh. Galiyeva, Candidate of Philological Sciences, Senior Researcher at the Department of Literary Studies Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, e-mail: nisanbedri@mail.ru

В редакцию статья поступила 17.07.2026, опубликована:

Галиева Л. Ш. Гази Кашшаф фондында Муса Җәлилгә бәйле материаллар (М. Җәлилнең тууына 120 ел тулу уңаеннан) // Гасырлар авазы – Эхо веков Echo of centuries. – 2026. – № 4. – С. 105-113.

Submitted on 17.07.2026, published:

Galiyeva L. Sh. *Gazi Kashshaf fondynda Musa Dzhalilge baile materiallar (M. Dzhalilneñ tuuyna 120 el tulu unyaennan)* [Materials on the life and work of Musa Jalil in the Gazi Kashshaf archival collection (on the occasion of the 120th anniversary of his birth)]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov* [Echo of centuries], 2026, no. 4, pp. 105-113.